БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 октябрь 2020 ел № 10

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декаберендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турында 2016 елның 23 декабрендәге 68 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә (2017 елның 24 июнендәге 88 номерлы, 2018 елның 1 нояберендәге 151 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 11 статьясына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәрнең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез милек милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) түләүсез нигездә катнашуы Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте турында законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм формада алынган яллаучы вәкиленең рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.»;

1.2. Нигезләмәнең 27.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27.3. Дисциплинар җәза бирәләрне куллану һәм бетерү тәртибе Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында, коррупциягә каршы тору турында законнарда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

1.3. Нигезләмәнең 28 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар белән коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен җәза бирәләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсез булган чорларын, аның чираттагы ялда (отпускта) булуын исәпкә алмыйча, муниципаль хезмәткәрләрнең коррупцион хокук бозуы турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм

коррупцион хокук бозу башкарылган көннән соң өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча башкару вакыты кертелми.»;

1.4. 29 пунктның 4 пунктчасына «(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр булдыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (шәхесләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшырырга» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау, законлылык һәм хокук тәртибе, җирле үзидарә буенча даими комиссиягә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р. Нотфуллин